**«Балачак әдипләре: иҗади җыентык»**

**республикакүләм**

**бәйге уздыру турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

**1. Гомуми нигезләмә.**

1.1. Бу нигезләмә «Балачак әдипләре: иҗади җыентык» республикакүләм бәйгесен (алга таба – Бәйге) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Бәйгене оештыручылар:

- «Сабантуй» журналы («ТАТМЕДИА» АҖ филиалы – «Салават күпере» журналы редакциясе»);
- «Ихлас» мультимедиа мәктәбе.

**2. Бәйгенең максаты һәм бурычлары.**

2.1. Бәйгенең максаты: үсеп килүче буында татар әдәбиятына, татар әдипләренә кызыксыну уяту, китап укуга мәхәббәт тәрбияләү.

2.2. Бәйгенең бурычлары:

- мәктәп укучыларында татар теленә, татар әдәбиятына мәхәббәт һәм әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү;
- татар әдипләренең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру;
- балаларны иҗади эзләнү эшенә җәлеп итү;
- иҗат итүче балаларга үз сәләтләрен күрсәтергә мөмкинлек тудыру.

**3. Бәйгедә катнашучылар.**

3.1. Бәйгедә «Балачак әдипләре» онлайн-дәресләрен караган 7 яшьтән алып 14 яшькә кадәрге мәктәп балалары катнаша. ZOOM-дәресләрдә катнашу – төп таләп булып тора.

3.2. Балалар эшләрен әзерләү ата-аналар һәм укытучылар ярдәме белән башкарылырга мөмкин.

**4. Бәйге шартлары:**

4.1.Катнашучылар түбәндәге шартлар белән килешәләр:

- «Ихлас» мультимедиа мәктәбенең «Балачак әдипләре» онлайн-дәресләрендә катнашу;
- «Балачак әдипләре» телеграм каналына язылу https://t.me/+kYtBD0qvTK0yNWYy;
- «Сабантуй» журналының YouTube каналына язылу https://youtube.com/@sabantyj
- Иҗади эш – әдәби җыентык ясау. Җыентыкны кулдан да, компьютерда басылган форматта да ясарга ярый. Иң мөһиме – җыентыкка онлайн дәрестә катнашкан барлык 12 әдип тә кергән булырга тиеш. Җыентыкның эчтәлеге – ирекле. Монда әдипләрнең биографиясе, фотосурәте, әсәрдән өзек яки шигырь дә урнаштырырга мөмкин. Эшне рәсемнәр белән дә бизәргә була.

5. **Бәйгене үткәрү срогы һәм тәртибе**.

5.1. Бәйге 2023 нче елның 1 нче февраленнән 30 нчы ноябренә кадәр үткәрелә.

5.2. Бәйгегә гариза һәм эшләр 2023 нче елның 1 ноябренә кадәр кабул ителә.

Гариза үрнәге беркетелгән (Кушымта).

5.3. Гариза тутыру һәм бәйгегә эшне җибәрү белән Катнашучы үзе турында шәхси мәгълүматларның дөреслеген гарантияли, эшнең фотосурәтен матбугат чараларында бастырып чыгаруга, интернет-ресурсларга урнаштыруга ризалыгын белдерә. Катнашучы турында шәхси мәгълүматлар бәйгене оештыручылар тарафыннан РФ законнары нигезендә эшкәртелә.

Катнашучы интернет-ресурсларда эшенә карата закон кысаларына сыя торган фикер алышуга каршылык күрсәтмәскә, Интернетта фикер алышуларда әдәплелек, этика кагыйдәләрен сакларга һәм закон нормаларын үтәргә бурычлы.

5.4. Эшләрне кабул итү тәртибе:

Эшләр, 420066, ТР, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт,

«Сабантуй» журналы редакциясе адресына почта аша кабул ителә.

Шушы адрес буенча эшләрне китереп бирергә дә була.

Белешмәләр өчен телефон: 89377715512

5.5. Эшләргә бәя бирү критерийлары:

- Иҗади җыентык ясауда креативлык;
- Җыентыкка барлык 12 әдипне дә кертү;
- Җыентыкны ясауда төрле алымнар куллану.

**6. Бүләкләү**

6.1. Бәйгедә катнашучыларның барысына да «Сабантуй» журналы тарафыннан бәйгедә катнашу турында сертификатлар җибәреләчәк. Укучы сертификатның кәгазь вариантына да заказ бирә ала, тик аны әзерләүгә киткән чыгымнарны капларга туры киләчәк. 1 сертификат бәясе – 200 сум.

6.2. Бәйгедә 10 җиңүче билгеләнәчәк. Аларга дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырыла. Аеруча актив мәктәпләр һәм укучыларга оештыручылар карары белән махсус бүләкләр билгеләнергә мөмкин.

6.3. Җиңүче һәм призерларны бүләкләү вакыты һәм урыны, бәйгегә йомгак ясаганнан соң, 2023 нче елның ноябрь аенда www.sabantuyjournal.ru сайтында игълан ителәчәк.

**7. Өстәмә нигезләмәләр**

7.1. Бәйгене оештыручылар, җиңүчеләрне игълан иткәнче, конкурска килгән эшләрнең фотосурәтен үз Интернет ресурсларында, шул исәптән «ВКонтакте» социаль челтәрендәге төркеменә урнаштырырга хокуклы. Онлайн тавыш бирү нәтиҗәләре бәйгегә нәтиҗә ясаганда исәпкә алынырга мөмкин, тик хәлиткеч роль уйнамый. Бәйгегә үз эшләрен җибәрүчеләр конкурсның нигезләмәсе белән килешүләрен белдерә.

**8. Белешмәләр өчен**

8.1. Бәйге белән бәйле бөтен сорауларны түбәндәге телефон номерына шалтыратып бирергә мөмкин: +79377715512 (Мөхетдинова Руфия Рифкат кызы)

**Кушымта**

# ГАРИЗА

| | |
|---|---|
| **ФИО** | |
| **Укучының яше** | |
| **Яшәү урыны** | |
| **Уку урыны, сыйныфы** | |
| **Элемтәгә керү өчен телефон номеры** | |
| **e-mail** | |
| **Җитәкченең ФИО** | |
| **Җитәкченең телефон номеры** | |
| **e-mail** | |